Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

30 октябрь 2020 ел № 8

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 30 сентябрендәге 323 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 нче кушымтасындагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы
муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме»

(сумнарда)

| «Вазыйфа исеме» | Вазыйфа оклад |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 34 494 |
| Район Советы аппараты җитәкчесе | 31 850 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 31 275 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 31 160 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 28 286 |
| Идарә башлыгы, мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, контроль орган аудиторы | 23 686 |
| Идарә башлыгы урынбасары, мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары (мөдире), Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 19 547 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, район башлыгы киңәшчесе, Башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 19 547 |
| Башкарма комитет идарәсе составында бүлек җитәкчесе | 19 547 |
| Бүлек мөдире | 18 167 |
| Баш белгеч | 17 477 |
| Әйдәп баручы белгеч | 16 443 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 14 718» |

1.2. карарга 3 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын, Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

(сумнарда)

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 34 967 |
| Башлык урынбасары | 31 469 |

| | |
|---|---|
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 31 469 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 22 029» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

4. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник», газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Ммуниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов